| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ |
|---|---|
| **Исполнительный комитет поселка городского типа Уруссу поселогы Ютазинского муниципального района** | **Ютазы муниципаль районы Урыссу шәһәр тибындагы Башкарма комитеты** |
| 423950, п.г.т. Уруссу, ул. Пушкина, 38<br>тел. 2-92-40<br>2-62-12 | 423950, Урыссу шәһәр тибындагы поселогы,<br>Пушкин урамы, 38<br>тел. 2-92-40<br>2-62-12 |


**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

№___4__ « 28 » 28.01.2015 ел

*Ютазы муниципаль районының шәһәр тибындагы Урыссу поселогы Башкарма комитетының 2014 елның 19 ноябрендәге «Муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында»гы 47нче карарына үзгәрешләр кертү хакында*

2014 елның 31 декабреннән «Россия Федерациясе чикләрендә йөрү ирегенә, тору һәм яшәү урынын сайлауга Россия Федерациясе Законына үзгәрешләр кертү һәм Россия Федерациясе закон актларының аерым нигезләмәләренең үз көчләрен югалтуын тану турында» 387 –ФЗ номерлы Федераль законның 2 статьясы һәм Ютазы районы прокурорының 2015 елның 21 гыйнварындагы 02-08-01-2015 номерлы протесты үз көченә керү сәбәпле.

1. Ютазы муниципаль районының Урыссу шәһәр тибындагы поселогы башкарма комитетының 2014 елның 19 декабрендәге 47 номерлы "Муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында" карарына үзгәрешләр кертергә:
   - Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Урыссу шәһәр тибындагы поселогы башкарма комитетында белешмә (өземтә) бирү буенча хезмәт күрсәтүнең административ регламентының 1 нче кушымтасына муниципаль хезмәт күрсәтү стандартының 2.5 пунктын «Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен, мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырыла торган документларның тулы исемлеге» кушымтасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"1.Яшәү урыныннан, йорт кенәгәсеннән белешмә алу өчен, элекке яшәү урыныннан белешмә алу өчен:

1.1. Шәхесне раслаучы документлар.

1.2. Йорт кенәгәсе.

1.3. Индивидуаль торак йортка хокуклар турындагы документ (индивидуаль торак йортка хокукны дәүләт теркәвенә алу турында таныклык йә техник (кадастр) паспорт, йә БТИ Ростехинвентаризация-Федераль филиалы, Татарстан Республикасы буенча филиалыннан хокук ияләре турында белешмә).

2.Гаилә составы турында белешмә алу өчен:

2.1. Шәхесне раслаучы документлар.

2.2. Йорт кенәгәсе.

2.3. Соралган адрес буенча теркәлгән гаиләнең барлык әгъзаларының туганлыгын раслый торган документлар (паспортлар, туу турында таныклыклар, никахлашу турында таныклык).

3.Үлем көненә үлгән кешенең яшәү урыныннан белешмә алу өчен:

3.1. Шәхесне раслаучы документ.

3.2. Йорт кенәгәсе.

3.3. Үлем турында таныклык (төп нөсхә).

3.4. Соралган адрес буенча теркәлгән гаиләнең барлык әгъзаларының туганлыгын раслый торган документлар (балалар туу турында таныклыклар, никахлашу турында таныклыклар).

4. Хуҗалык кенәгәсеннән өземтә алу өчен түбәндәгеләрне тапшырырга кирәк:

4.1 хуҗалык кенәгәсеннән өземтә бирүне сорап, ирекле формада гариза;

4.2. хокук иясенең шәхесен раслый торган документ;

4.3.җир кишәрлегенең үлгән хуҗасының үлеме турында таныклык күчермәсе;

4.4.җир кишәрлегендә урнашкан йортка (әгәр булса, башка объектларга) хокук билгели торган документларның күчермәләре;

Җитәкче вазыйфаларын башкаручы Р.Ф. Вәдигуллин

Т.Г. Исмәгыйлева
2-92-40